**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О местном самоуправлении в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
21 сентября 2017 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 28 июля 2004 года № 45-ЗРТ «О местном самоуправлении в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 7 (II часть); 2005, № 2, № 4 (I часть), № 6 (II часть), № 11; 2006, № 4, № 7 (I часть); 2007, № 7 (I часть), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I часть); 2010, № 7 (II часть), № 12 (II часть); 2011, № 3, № 11 (I часть); 2012, № 7 (I часть), № 11 (I часть); 2013, № 3, № 7, № 12 (I часть); 2014, № 5, № 11 (VI часть); 2015, № 7 (I часть), № 11 (I часть); 2016, № 3, № 5, № 6 (I часть), № 9 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 1 (I часть), № 27 (I часть), № 55 (I часть) следующие изменения:

1) часть 7 статьи 6 изложить в следующей редакции:

«7. Муниципальные нормативные правовые акты, затрагивающие права, свободы и обязанности человека и гражданина, устанавливающие правовой статус организаций, учредителем которых выступает муниципальное образование, а также соглашения, заключаемые между органами местного самоуправления, вступают в силу после их официального опубликования (обнародования).»;

2) в статье 7:

а) абзац первый части 8 изложить в следующей редакции:

«8. Изменения и дополнения, внесенные в устав муниципального образования и изменяющие структуру органов местного самоуправления, разграничение полномочий между органами местного самоуправления (за исключением случаев приведения устава муниципального образования в соответствие с федеральными законами, а также изменения полномочий, срока полномочий, порядка избрания выборных должностных лиц местного самоуправления) вступают в силу после истечения срока

полномочий представительного органа муниципального образования, принявшего муниципальный правовой акт о внесении указанных изменений и дополнений в устав муниципального образования, а в случае формирования представительного органа муниципального района в соответствии с частью 3 или пунктом 1 части $3^1$ статьи 22 настоящего Закона – после истечения срока полномочий главы муниципального образования, подписавшего муниципальный правовой акт о внесении указанных изменений и дополнений в устав муниципального образования.»;

б) дополнить частью $8^1$ следующего содержания:

«$8^1$. Изменения и дополнения в устав муниципального образования вносятся муниципальным правовым актом, который может оформляться:

1) решением представительного органа (схода граждан) муниципального образования, подписанным его председателем и главой муниципального образования либо единолично главой муниципального образования, исполняющим полномочия председателя представительного органа (схода граждан) муниципального образования;

2) отдельным нормативным правовым актом, принятым представительным органом (сходом граждан) и подписанным главой муниципального образования. В этом случае на данном правовом акте проставляются реквизиты решения представительного органа (схода граждан) о его принятии. Включение в такое решение представительного органа (схода граждан) переходных положений и (или) норм о вступлении в силу изменений и дополнений, вносимых в устав муниципального образования, не допускается.»;

в) дополнить частью 10 следующего содержания:

«10. Изложение устава муниципального образования в новой редакции муниципальным правовым актом о внесении изменений и дополнений в устав муниципального образования не допускается. В этом случае принимается новый устав муниципального образования, а ранее действующий устав муниципального образования и муниципальные правовые акты о внесении в него изменений и дополнений признаются утратившими силу со дня вступления в силу нового устава муниципального образования.»;

3) часть 1 статьи 15 дополнить пунктом $4^1$ следующего содержания:

«$4^1$) осуществление в ценовых зонах теплоснабжения муниципального контроля за выполнением единой теплоснабжающей организацией мероприятий по строительству, реконструкции и (или) модернизации объектов теплоснабжения, необходимых для развития, повышения надежности и энергетической эффективности системы теплоснабжения и определенных для нее в схеме теплоснабжения в пределах полномочий, установленных Федеральным законом «О теплоснабжении»;»;

4) часть 1 статьи $15^1$ дополнить пунктом 16 следующего содержания:

«16) оказание содействия развитию физической культуры и спорта инвалидов, лиц с ограниченными возможностями здоровья, адаптивной физической культуры и адаптивного спорта.»;

5) часть 1 статьи $16^1$ дополнить пунктом 14 следующего содержания:

«14) оказание содействия развитию физической культуры и спорта инвалидов, лиц с ограниченными возможностями здоровья, адаптивной физической культуры и адаптивного спорта.»;

6) часть 1 статьи 17 дополнить пунктом $4^1$ следующего содержания:

«$4^1$) осуществление в ценовых зонах теплоснабжения муниципального контроля за выполнением единой теплоснабжающей организацией мероприятий по строительству, реконструкции и (или) модернизации объектов теплоснабжения, необходимых для развития, повышения надежности и энергетической эффективности системы теплоснабжения и определенных для нее в схеме теплоснабжения в пределах полномочий, установленных Федеральным законом «О теплоснабжении»;»;

7) часть 1 статьи $17^1$ дополнить пунктом 17 следующего содержания:

«17) оказание содействия развитию физической культуры и спорта инвалидов, лиц с ограниченными возможностями здоровья, адаптивной физической культуры и адаптивного спорта.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань,Кремль
07 октября 2017 года
№ 75-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 21 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 7 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“7. Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы, муниципаль берәмлек тарафыннан гамәлгә куелган оешмаларның хокукый статусын билгеләүче муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр үз көчләренә рәсми басылып чыкканнан (игълан ителгәннән) соң керә.”;

2) 7 статьяда:

а) 8 өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“8. Муниципаль берәмлек уставына кертелгән һәм җирле үзидарә органнарының структурасын, җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләр бүлешүне (муниципаль берәмлек уставы федераль законнарга туры китерелгән очраклардан, шулай ук җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары вәкаләтләре, аларның вәкаләтләр чоры һәм сайлану тәртибе үзгәрүдән тыш) үзгәртә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр муниципаль берәмлек уставына күрсәтелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертү турында муниципаль хокукый акт кабул иткән

муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре чоры тәмамланганнан соң, муниципаль районның вәкиллекле органы әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлеше яисә $3^{1}$ өлешенең 1 пункты нигезендә формалашкан очракта – муниципаль берәмлек уставына күрсәтелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертү турында муниципаль хокукый актны имзалаган муниципаль берәмлек башлыгының вәкаләтләре чоры тәмамланганнан соң үз көченә керә.";

б) түбәндәге эчтәлекле $8^{1}$ өлеш өстәргә:

"$8^{1}$. Муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр муниципаль хокукый акт белән кертелә, ул түбәндәгеләр белән рәсмиләштерелергә мөмкин:

1) муниципаль берәмлек вәкиллекле органының (гражданнар җыенының) аның рәисе һәм муниципаль берәмлек башлыгы йә муниципаль берәмлек вәкиллекле органы (гражданнар җыены) рәисе вәкаләтләрен башкара торган муниципаль берәмлек башлыгы берүзе имзалаган карары;

2) вәкиллекле орган (гражданнар җыены) тарафыннан кабул ителгән һәм муниципаль берәмлек башлыгы имзалаган аерым норматив хокукый акт. Бу очракта әлеге хокукый актта вәкиллекле органның (гражданнар җыенының) бу карарны кабул итү турында реквизитлары күрсәтелә. Вәкиллекле органның (гражданнар җыенының) шундый карарына күчеш нигезләмәләре һәм (яисә) муниципаль берәмлек уставына кертелә торган үзгәрешләрнең һәм өстәмәләрнең үз көченә керүе турында нормалар кертү рөхсәт ителми.";

в) түбәндәге эчтәлекле 10 өлеш өстәргә:

"10. Муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт белән муниципаль берәмлек уставын яңа редакциядә бәян итү рөхсәт ителми. Бу очракта муниципаль берәмлекнең яңа уставы кабул ителә, ә муниципаль берәмлекнең элек гамәлдә булган уставы һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль хокукый актлар муниципаль берәмлекнең яңа уставы гамәлгә кергән көннән үз көчләрен югалткан дип танылa.";

3) 15 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $4^{1}$ пункт өстәргә:

"$4^{1}$) җылылык белән тәэмин итүнең бәя зоналарында җылылык белән тәэмин итү объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең һәм (яисә) модернизацияләүнең җылылык белән тәэмин итү системасын үстерү, аның ышанычлылыгын һәм энергетик файдасын арттыру өчен кирәкле булган һәм җылылык белән тәэмин итү схемасында аның өчен билгеләнгән чараларын бердәм җылылык белән тәэмин итү оешмасы тарафыннан үтәүгә муниципаль контрольне "Җылылык белән тәэмин итү турында" Федераль законда күрсәтелгән вәкаләтләр кысаларында гамәлгә ашыру;";

4) $15^{1}$ статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 16 пункт өстәргә:

"16) инвалидлар, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен физик культураны һәм спортны, адаптив физик культураны һәм адаптив спортны үстерүгә булышлык күрсәтүгә.";

5) $16^{1}$ статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:

“14) инвалидлар, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен физик культураны һәм спортны, адаптив физик культураны һәм адаптив спортны үстерүгә булышлык күрсәтүгә.”;

6) 17 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $4^{1}$ пункт өстәргә:

“$4^{1}$) җылылык белән тәэмин итүнең бәя зоналарында җылылык белән тәэмин итү объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең һәм (яисә) модернизацияләүнең җылылык белән тәэмин итү системасын үстерү, аның ышанычлылыгын һәм энергетик файдасын арттыру өчен кирәкле булган һәм җылылык белән тәэмин итү схемасында аның өчен билгеләнгән чараларын бердәм җылылык белән тәэмин итү оешмасы тарафыннан үтәүгә муниципаль контрольне “Җылылык белән тәэмин итү турында” Федераль законда күрсәтелгән вәкаләтләр кысаларында гамәлгә ашыру;”;

7) $17^{1}$ статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 17 пункт өстәргә:

“17) инвалидлар, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен физик культураны һәм спортны, адаптив физик культураны һәм адаптив спортны үстерүгә булышлык күрсәтүгә.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 07 октябрь
№ 75-ТРЗ